# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Кара һәм төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын җыю, эшкәртү, реализацияләү һәм Татарстан Республикасыннан читкә чыгару кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылык турында**

Әлеге Закон кара һәм төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын җыю, эшкәртү, реализацияләү һәм Татарстан Республикасыннан читкә чыгару өлкәсендәге хокук бозуларны кисәтүгә юнәлдерелгән.

1 статья. Кара һәм төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын лицензиясез җыю, эшкәртү, реализацияләү һәм Татарстан Республикасыннан читкә чыгару

Кара һәм төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын лицензиясез җыйган, эшкәрткән, реализацияләгән һәм Татарстан Республикасыннан читкә чыгарган өчен-

юридик затларга, кара һәм төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын конфискацияләп, хезмәт өчен түләүнең утыздан алып йөз минималь күләменә кадәр, урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең уннан алып илле минималь күләменә кадәр, индивидуаль эшкуарларга, төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын конфискацияләп, хезмәт өчен түләүнең биштән алып егерме минималь күләменә кадәр штраф салына.

**2 статья.** Кара һәм төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын халыктан билгеләнгән тәртипне бозып кабул итү

Кара һәм төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын халыктан билгеләнгән тәртипне бозып кабул иткән өчен -

юридик затларга, кара һәм төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын конфискацияләп, хезмәт өчен түләүнең утыздан алып йөз минималь күләменә кадәр, индивидуаль эшкуарларга, законсыз алынган кара һәм төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын конфискацияләп, хезмәт өчен түләүнең уннан алып утыз минималь күләменә кадәр штраф салына.

**3 статья.** Кара һәм төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын Татарстан Республикасыннан читкә законсыз чыгару

Сәнәга һәм көнкүрешнең кара һәм төсле металлар ватыкларын һәм калдыкларын Татарстан Республикасыннан читкә тиешле рөхсәттән башка чыгарган өчен -

юридик затларга, кара һәм төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын конфискацияләп, хезмәт өчен түләүнең йөздән алып биш йөз минималь күләменә кадәр, индивидуаль эшкуарларга, кара һәм төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын конфискацияләп, хезмәт өчен түләүнең уннан алып илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

**4 статья.** Кара һәм төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын ташу өчен кабул иткәндә билгеләнгән тәртипне бозу

Кара һәм төсле металл сәнәга һәм көнкүрешнең ватыкларын һәм калдыкларын Татарстан Республикасыннан читкә ташу өчен тимер юл, автомобиль, һава һәм су транспорты предприятиеләренең билгеләнгән тәртипне бозып кабул иткән өчен -

юридик затларга хезмәт өчен түләүнең утыздан алып йөз минималь күләменә кадәр, урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең уннан алып утыз минималь күләменә кадәр штраф салына.

222

5 статья. Административ хокук бозулар турында беркетмәләр

Бу Законда каралган административ хокук бозулар турындагы беркетмәләр эчке эшләр органнарының моңа вәкаләтле урындагы затлары тарафыннан төзелә һәм биш көн вакыт эчендә судка җибәрелә.

6 статья. Административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау

Әлеге Законда каралган административ хокук бозулар турындагы эшләр административ хокук бозулар турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытта район (шәһәр) суды (судьясы) тарафыннан карала.

7 статья. Штрафлар суммасын бүлү

Әлеге Законда каралган хокук бозулар өчен җыелган штрафлар суммасының 50 проценты - Татарстан Республикасының республика бюджетына, 50 проценты административ материалларны карау урыны буенча шәһәрләрнең һәм районнарның җирле бюджетларына җибәрелә.

8 статья. Әлеге Законны гамәлгә кертү тәртибе

Әлеге Закон матбугатта рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1999 елның 17 ноябре
№ 2441